**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

09.01.2019г. — №2

Яңа Әлем авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең эш планын раслау турында

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау проблемаларын комплекслы хәл итү, балалар һәм яшүсмерләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру өчен хокукый, социаль-икътисадый шартлар тудыру максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

Расларга:

1. 2019 елга Яңа Әлем авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау чаралары планы (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Яңа Әлем авыл җирлегенең рәсми сайтында : http://aktanysh.tatar.ru/rus/aktanysh/poselenia.htm.урнаштырырга
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Әлем авыл җирлеге башлыгы — Д.М.Әнвәрова

Башкарма комитет җитәкчесе карарына
09.01.2019 ел,
1 нче кушымта

**Яңа Әлем авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе нигезләмәсе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Яңа Әлем авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органы булып тора.

1.2. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия үз эшчәнлегендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе белән хезмәттәшлек итә.

## II. Иҗтимагый комиссия вәкаләтләре

2.1. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- үз компетенциясе чикләрендә җирлектә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау чараларында гамәлдәге законнар нигезендә катнаша;

- Яңа Әлем авыл җирлеге территориясендә яшәүче социаль куркыныч хәлдәге балаларны һәм гаиләләрне ачыклый;

- сукбайлыкка, соранугa мохтаҗ балаларны ачыклау буенча рейдлар уздыруда билгеләнгән тәртиптә катнаша;

- балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуның ачыкланган фактлары турында компетентлы органнарга хәбәр итә;

- Актаныш районы Башкарма комитеты каршындагы опека һәм попечительлек органнарына дәүләт ярдәменә мохтаҗ балигъ булмаганнарны оештыру һәм аларга ярдәм итү турында тәкъдимнәр кертә;

- балигъ булмаганнар һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән индивидуаль-профилактик һәм тернәкләндерү эшендә катнаша;

- җирле үзидарә органнары һәм балигъ булмаганнарның балалар яши торган социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр белән эшләве турында күзәтүчесез калуны һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләре белән мәгълүмати алмашуны гамәлгә ашыра;

- балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик эш үткәрү кирәклеге турында мәгълүматны балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тиешле органнарга җибәрә;
- үз утырышларында социаль ятимлекне, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, аларның хокукларын яклау мәсьәләләре карала.

## III. Иҗтимагый комиссия составы

3.1. Иҗтимагый комиссия составы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

3.2. Комиссия составына кимендә биш кеше керә: балигъ булмаганнар белән эшләү тәҗрибәсе булган комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары (балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы хезмәткәрләре, шулай ук башка оешма вәкилләре).

3.3. Комиссия әгъзаларының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру түләүсез нигездә башкарыла.

3.4. Комиссия эшчәнлегенә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе җитәкчелек итә.

3.5. Комиссия рәисе комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны ачыклау, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау эшен оештыра, комиссия утырышларын алып бара, комиссия тарафыннан кабул ителә торган документларга, комиссия эшләре номенклатурасына кул куя.

3.6. Комиссия рәисе урынбасары балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең рәисен ул югында алыштыра, комиссия карарларының, планнарының үтәлешен тикшереп тора, комиссия эшен алып бара.

## IV. Иҗтимагый комиссия эшен оештыру

4.1. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе агымдагы елга комиссия эше планы нигезендә һәм кичектергесез килеп чыккан мәсьәләләрне оператив хәл итү кирәклеген исәпкә алып үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

4.2. Чираттагы елга комиссия эше планы проектына тәкъдимнәр комиссиянең әгъзалары, башка кызыксынган органнар һәм оешмалар тарафыннан агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча кертелә.

4.3. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышлары кирәк саен уздырыла, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла һәм әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия шулай ук күчмә утырышлар үткәрергә мөмкин.

4.4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышында сораулар комиссиянең расланган рәисе тарафыннан көн тәртибенә ярашлы рәвештә карала.

Комиссия әгъзалары тәкъдиме яисә комиссия рәисе карары буенча утырышта көн тәртибендә каралмаган, әмма оператив коллегиаль чишелеш таләп ителгән өстәмә мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.5. Утырыш барышында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

- утырышның көн тәртибе һәм эш тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә;

- докладчылардан һәм фикер алышуларда чыгыш ясаучылардан карала торган мәсьәләләр буенча өстәмә аңлатмалар алырга;

- карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә.

4.6. Карар комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

4.7. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм кирәк булганда тиешле органнарга һәм учреждениеләргә мәгълүмат бирү өчен җирлек территориясендә җибәрелә.

Башкарма комитет җитәкчесе карарына
09.01.2019 ел,
2 нче кушымта

**Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең эш планы**

| № т/б | Чара | Үтәү сроклары | Башкару өчен җаваплы | Чара кем белән берлектә үткәрелә |
|---|---|---|---|---|
| | **Оештыру-методик эш** | | | |
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы (Татарстан Республикасы буенча Россия ЭЭМ беркетмәләре һәм тәкъдимнәре буенча балигъ булмаганнарга һәм аларның ата-аналарына карата материалларны карау  Актаныш районында белем бирү учреждениеләренең тәкъдимнәре һәм үтенечләре, гражданнарның шикаятьләре, торак шартларын тикшерү актлары һ. б.) | кварталга 1 тапкыр | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе һәм секретаре | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |
| 2. | Яңа Әлем авыл җирлегендә КДН һәм ЗПның күчмә утырышларын үткәрү | квартал саен | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең социаль имин булмаган гаиләләргә рейдлары | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында алкоголизмны профилактикалау максатыннан яшүсмерләр (дискотекалар, урамнар) концентрациясе урыннары буенча рейдлар | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе,мәгариф, мәдәният учреждениеләре составы |
| 5. | Сату нокталары буенча рейдлар | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |
| 6. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы КДН һәм ЗП утырышларында чыгарылган штрафлар түләүдән тайпылучы гражданнар буенча рейдлар | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм аларны КДНга ЗП һәм ПДН исәпкә кую | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |
| 8. | Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча яшүсмерләрне һәм аларның ата-аналарын кабул итү | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |
| 9. | Гаилә көненә, Балаларны яклау көненә, Яңа елга чаралар оештыру һәм уздыру | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, җирлек мәдәният учреждениесе составы |

**Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышларына карау өчен чыгарыла торган сораулар**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе эшенә йомгак ясау | Ел ахырында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларның һәм җинаятьләрнең торышы турында | квартал саен | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы |
| 3. | Дәресләргә керешмәгән балалар турында һәм мондый фактларны булдырмау буенча җирлекнең мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрелгән чаралар турында һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның балаларны мәктәпкә кайтару хокукларын яклау комиссиясе составы турында мәгълүмат | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, мәгариф учреждениеләре составы |
| 4. | Балигъ булмаганнар һәм шартлы хөкем ителгәннәр белән индивидуаль профилактик эш башкару турында | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, мәгариф учреждениеләре составы |
| 5. | Яшәү урыны буенча балигъ булмаганнарның ялын оештыру турында | Ел дәвамында | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, мәгариф учреждениеләре составы |